Аккуз төп гомуми белем бирү мәктәбе пед утырышында кабул ителде
Протокол № 1 «31» 08. 2022

Кулланылышка кертелде
Пр.№ ____
«31» 08 2022

Раслыйм:
Аккуз төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры
____ Р.Ф Зямилов.

# Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Аккуз төп гомуми белем бирү учреждениесенең структур -бүлекчәсе Аккуз балалар бакчасы"ның

## еллык эш планы

2022 – 20223нче уку елы

2022 ел

**Еллык планның эчтәлеге**

Балалар бакчасы  турында мәгълумат..............................................................3
2021-2022 уку елына анализ....................................................................................4
Максат һәм бурычлар ..............................................................................................8
Кадрлар арасында эш бүленеше..............................................................................8
Белем күтәрү аттестация үтү графигы ...................................................................9
Белем турында законнар үтәлеше............................................................................9
Тәрбиячеләрнең профессиональ осталыкларын үстерү..........................................10
Методик темалар.......................................................................................................10
Педагогик киңәшмәләр.............................................................................................10
Консультатив пункт эшчәнлеге һәм планы.............................................................11
Ачык чаралар.............................................................................................................12
Смотр-конкурслар......................................................................................................13
Район буенча үткәрелә торган конкурслар..............................................................14
Күңел ачу кичәләре планы.........................................................................................15
Атналыклар.................................................................................................................15
Җитәкчелек һәм контроль:.........................................................................................15
Фронталь һәм тематик тикшерүләр...........................................................................15
Оператив тикшерүләр.................................................................................................15
Оператив тикшерү үткәрүнең циклограммасы.........................................................15
Мәктәп белән элемтә планы........................................................................................18
Ата-аналар белән эш....................................................................................................20
Бакчага йөрмәгән балалар белән эш..........................................................................21
Телләр турындагы законны тормышка ашыру планы............................................22
Сәламәтләндерү   чыныктыру планы.........................................................................23
Экскурсияләр планы....................................................................................................24
Производство киңәшмәләре.......................................................................................24
Административ хуҗалык эшләре...............................................................................25

**Балалар бакчасы турында мәгълумат**

**Аккуз** балалар бакчасы 1966 нчы елның 10 нчы октябрендә ачыла
2002 нче елның октябрь аенда балалар бакчасы мәктәп бинасына күчте. Бакчаның мәйданы 750 кв.м. Шуның эченнән группа бүлмәсе , методик бүлмә , коридор , склад ,раздевалка , йокы бүлмәсе . Участок 752 кв.м. Уен зонасы 650. кв.м, шуның эченнән спорт площадкасы чәчәклекләр 230 кв.м.

**Бакчаның материаль-техник базасы яхшы.** Балалар бакчасы мебельләр белән тәэмин ителгән.. Бакчага су кергән, канализация бар. Балаларга ашарга пешерү өчен 4 камфоркалы элетр плиткасы куелган. Кухня мәктәп белән берлектә, мәктәп ягында. Уен һәм спорт площадкасы кирәкле инвентарьлар белән җиһазланган. Навесы бар.

**Педагогик кадрлар белән тәэмин ителеш**

1. Гайсина. Регина Малик кызы - тәрбияче, белеме махсус урта
2. Галлямова Флурә Габделххәй кызы - бакча мөдире, белеме югары, 2020 нчы елда аттестация үтте, 2020 нче елда белем күтәрү курсында булды.

**Башка хезмәткәрләр турында белешмә.**

1.Гафурова Илсояр Хәмзә кызы - пешекче, махсус урта белемле 4 нче разрядлы пешекче.

2 Шарипова Раушания. Мэхиян кызы - кече тәрбияче.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “Акку балалар бакчасы”
Адрес: 423744, Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Аккуз авылы
Г.Тукай урамы 1а. Телефон 3-80-22
Бакча мөдире: Галлямова Флурә Габделхәй кызы

Тәрбияче: Гайсина Регина Малик кызы

Бала саны-8

Балалар бакчасында 1 төркемдә 2 төркемчә эшли:

Мәктәпкә әзерлек төркеме- 4 бала
Уртанчылар төркеме: - 4 бала

**Аккуз балалар бакчасының 2021-2022 нче уку елында тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенә анализ.**

Балалар бакчасында 2021-2022 нчы уку елында барлыгы 6 бала тәрбия һәм белем алды.
Авыл буенча бала саны 2 бакчага тартылыш 100 %
Тәрбияче балаларны 2 подгруппага бүлеп эшләде:
Уртанчылар
Мәктәпкә әзерлек

***Балалар бакчасы түбәндәге бурычларны куеп эшләде***:

1. ФДББС шартларында балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессында яңа технологияләр, яңа алымнар куллану.

2. Балаларны ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, УМК куллану.
3. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру;
4. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда экологик күнекмәләр формалаштыруны дәвам итү.
5. Балаларда үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыру, аларның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган җирен хөрмәт итүче патриот шәхес тәрбияләү.

Балалар бакчасы үз эшчәнлеген федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп алып барды. Ел башында ФГОС туры китереп чаралар планы эшләдек, район буенча һәм зоналарда үткән семинарларда, киңәшмәләрдә яңа стандартларны өйрәндек,ачык шөгыльләр карадык. Яңа федераль дәүләт мәгариф стандартына күчү стандартның гамәлдәгесеннән аермасы бала шәхесенең игътибар үзәгенә куелуында. Без, тәрбиячеләр баланы шәхес итеп тәрбияләргә, аның индивидуаль үзенчәлекләрен искә алырга, иҗади фикерләү дәрәҗәсен үстерергә, акыл хезмәте өчен кирәкле шартлар, мохит тудырырга, аңа күнекмәләр бирергә, эшкә өйрәтергә тиешбез. Аннан соң балаларга белем бирү өстендә эшчәнлек алып барыла. Ел башында стандарт таләпләрен һәм үрнәк белем бирү программасына туры китереп үзебезнең төп белем бирү программасын төзедек.Ул 2 өлештән тора. Беренчесе мәҗбури өлеш, икенчесе белем бирүдә катнашучылар төзегән вариатив өлеш. Белем бирү программасының федераль өлеше балаларны дөнья, Россия мәдәнияте, әдәбияте, тарихы белән таныштыруны бурыч итеп куя, ә милли – төбәк өлеше билгеле бер төбәкнең мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тел һәм әдәбиятне, тарих, география һ.б.үзенчәлекләрен белү зарурлыгын билгели. Бу юнәлештә Резеда Шаехованың милли һәм региональ үзенчәлекләрне исәпкә алып төзегән “Төбәкнең мәктәпкчә белем бирү программасы”н үз эшебездә уңышлы кулландык. Бу китапта педагогик эшнең бурычлары 4 юнәлештә бирелгән:

- Физик үсеш, социаль-шәхси, танып-белү, сөйләм, нәфис-нәфәсәти үсеш.

Шулай ук Закирова, Борһанова, Галиеваларның “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү. Программаның милли-төбәк юнәлеше” дигән китабын татар халкының милли мәдәнияте, халык авыз иҗаты, җырлары белән таныштыру һ.б. буенча кулландык. Бу программа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары куйган 3 төп бурычны үз эченә ала.: тәрбияви, үстерү, белем бирү бурычлары. ФГОС һәм милли-төбәк компоненты куйган бурычларны гамәлгә ашыру өчен балалар бакчасында предметлы үстерешле мохит тудырдык. Туган як тарихы белән таныштыру буенча туган як почмагы, балаларны ике телгә өйрәтү буенча татар һәм рус почмаклары булдырдык, балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча почмак, театр почмагы, сюжетлы-рольле уеннар өчен зоналар, яңарттык.

Тәрбияче һәм җитәкче тарафыннан балалар бакчасының укыту-тәрбия,
календарь планнары уку графигы, режим, расписаниеләр төзелде, һәм шулар нигезендә ел буена системалы эш алып барылды.

Балаларга тәрбия һәм белем бирүдә УМК буенча кайткан китаплар,дисклар, күрсәтмә һәм таратма материаллар кулланылды

**Район күләмендә оештырылган түбәндәге конкурсларда катнаштык:**

- “Җәлил укулары”
- “Татар кызы, татар егете-номинаөия”
- “Буду бдителҗным на элҗду”

“ Яна ел маңаралары”

“ Символ года”

“ Йолдызлык “ -нәфис суз- Янсубина Юлия

Давлетов Султан ялгыз бию

Музей видо рулик

“ЭКО ВЕСНА

**Балаларның сәламәтлекләре**.

Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге бурычларны куйдык:
-хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- бала организмы өчен туклану иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
-организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр баланың үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
-балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
-мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклакп үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; сәламәтлек почмагы, спорт участоклары яңартылды, экскурсияләр оештырылды, анда дару үләннәре турында әңгәмәләр үткәрелде, үләннәрне танырга өйрәтелде; хәрәкәтле уеннар ечен кулланма жиһазлар тупланды; спорт төрләрен кулланып бәйрәмнәр, хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстерү буенча күңел ачу кичәләре уздырылды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче чиратта балаларның активлыгына игътибар ителде

Бакчада физкультура дәресе өлкәннәр төркемендә өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Дәресләрдә түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
- заман таләпләренә туры килгән прграммалар куллану, яңалыкка омтылу.

Балаларны сәламәтләндерү программасы түбәндәге эш төрләрен кертеп төзелде:

чыныктыру ысуллары;

- грипптан, салкын тиюдән саклану чаралары;
- фитотерапия;
- яссытабанлыкны, күз күреме бозылуны кисәтү;
- гәүдәне торышына игътибар.

Грипп, ОРЗ чорында тәрбияче, кече тәрбияче группада сарымсак , суганнарны турап бүлмәләргә куйдылар.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш белән тукландырылды.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: авырып килүче балалар булмадылар.

Балаларга юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча тәрбияче тарафыннан тематик-перспектив план төзелде. Шул план нигезендә тәрбияче дәрес эшкәртмәләре төзеде. Шулай ук балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча табышмаклар, тизәйткечләр, такмаклар тупланды. Коридорда балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча шөгыльләр өчен кирәк булган күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, юл макетлары, светофор, юл билгеләре, рульләр, милиция фуражкалары, юл күрсәтүче таяклар һ.б. тупланган., тәрбиячегә, балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча ярдәмгә махсус әдәбият тупланды.

Балаларны үзебез яшәгән авыл белән таныштыру һәм үз төбәгеңә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан ел буена экскурсияләр оештырабыз: төрле оъектларга: китапханәгә, мәдәният йортына, авыл советына, медпунктка, мәчеткә. Чишмәгә, басудагы игеннәрне карарга, яланга, тауга да ел сезонына карап экскурсияләр оештырдык. Экскурсиядә күргәннәр, тәэсирләре белән кайткач балалар белән әңгәмәләр оештырыла.

Бу эшләр белән бергә милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына. Октябрьдә “Сөмбелә” бәйрәме, өлкәнәребезгә багышланган “Минем кадерлеләрем”, ноябрьдә “Әниләр көне”, декабрьдә “Чыршы бәйрәме”, февраль аенда «Әтием горурлыгым”, ”Туган тел бәйрәме”, март аенда “ 8 нче Март бәйрәме”, “Кошлар - безнең дуслар”, бәйрәмнәре үткәрелде. Апрель аенда Г.Тукай бәйгесенә онлайн катнаштыкк. Бөек Җиңүнең 75 еллыгында балалар онлайн чыгыш ясадылар. Ел башында ук чаралар планы төзелде. Эшне план нигезендә алып барырга тырыштык. Балаларга сугыш турында, аның бик аяныч нәрсә икәнлеген балаларга аңлаттык, шигырьләр, хикәяләр укыдык, рәсем конкурслары үткәрдек, шушы темада почмак булдырдык.

Балаларны үзебез яшәгән авыл белән таныштыру һәм үз төбәгеңә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан ел буена экскурсияләр оештырабыз: төрле обьектларга: китапханәгә, мәдәният йортына, авыл советына, медпунктка, мәчеткә. Чишмәгә, басудагы игеннәрне карарга, яланга, тауга да ел сезонына карап экскурсияләр оештырдык. Экскурсиядә күргәннәр, тәэсирләре белән кайткач балалар белән әңгәмәләр оештырыла.

Экологик тәрбия бирү буенча да бик күп күләмдә эш алып барылды. Бүлмәдә яшь үзенчәлегенә һәм ел фасылларына туры китереп, табигать почмагы төзелде. Күп күрсәтмә җиһазлар, дидактик уеннар, эш кораллары, кече аквариум булдырылды.Табигать календарендә һава торышын билгеләделәр.Арыш, бодай, борчак, суган утыртып, аларның шытып чыгуын, үсүен күзәтеп язып бардылар. Бүлмә гөлләренең паспортларын тутыру буенча эшчәнлекләрен дәвам иттеләр.

Балаларга табигатьнең гүзәллеге, аның байлыгы белән таныштыру, үсемлек, хайваннарны таный белергә өйрәтү, аларга карата сакчыл караш тәрбияләү максатыннан, планлы рәвештә эш алып барылды Бала иң беренче чиратта үзе яшәгән төбәкнең экологик хәлен белергә тиеш, шуның өчен дә һәр ел фасылында табигатькә экскурсияләр оештырылды. Балалар табигатьнең төрле халәтен, бөҗәкләрне, чәчәкләрне, күк йөзен күзәттеләр, яфраклар, дару үләннәрен җыйдылар, бакча мәйданчыгын чүпләрдән арындырдылар, хайваннар белән таныштылар. Күзәтү, хезмәт аша балалар табигатьнең чисталыгын сакларга, матурлыгын күрә белергә өйрәнделәр.

Һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк рассадалы, суган утырттык. Бакчадагы язгы эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды: бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, сирәкләү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. . Көзен участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, коелган яфраклардан арындырдык. Кыш көне, кардан сыннар ясау, кар көрәү, тубәләрне боздан, кардан арындыру кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга балалар көн саен прогулкага чыккач җим салдылар.

Балаларның экологик белемнәрен киңәйтү, максатыннан тәрбияче табигать материаллары тупланды. Бүлмәләрдә бик күп төрле гөлләр үстердек. Тәрбияче балалар белән берлектә гөлләрне карап, тәрбияләп, гөлләрне танырга, исемнәрен әйтә белергә өйрәтте.

**Педагогик кадрлар белән эш.** Ел дәвамында тәрбияченен еллык, айлык, атналык планнары тикшерелеп торылды. Занятиеләргә кереп алар анализланды, кимчелекләрне бетерү буенча киңәшләр бирелде. Балаларны ике теллелеккә өйрәтүнең торышы буенча тематик тикшерү үткәрелде. Педагогик процесс күзәтелде, тәрбияченең документацияләре, балаларның эш дәфтәрләре тикшерелде, тәрбияче һәм балалар белән әңгәмә үткәрелде, үстерешле предметлы тирәлек, ата-аналар белән эш формалары ачыкланды.. Тикшерү нәтиҗәләре буенча справка язылды, тәрбиячегә төрле темаларда консультацияләр бирелде. Оператив тикшерү циклограммасы буенча оператив тикшерүләр үткәрелеп справкалары язылды, мөдир яны киңәшмәсендә кимчелекләр, уңышлы яклар аңлатылды. Балалар бакчасы Аккуз төп гомуми белем бирү мәктәбенең структура бүлеге булганлыктан мәктәпнең педагогик утырышларында катнаштык. 1 нче утырышта эш планнары, эш программалары, бакчаның локаль актлары кабул ителде, 2 нче утырышта катнашып балалар белән ел башында үткәрелгән диагностика нәтиҗәләренә анализ бирдек, 3 нче утырышта "Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү" һәм "Балалар бакчасында физик тәрбия" дигән темада чыгыш ясадык. 4 нче утырышта еллык эш нәтиҗәләренә анализ бирелде.

**Ата-аналар белән эш.**Уку елы башында ата-аналар белән бакча арасында килешү төзелде. Әти-әниләр катнашында гаилә бәйрәмнәре, спорт ярышлары оештырылды. Бу чаралар үзләренең мавыктыргыч булулары белән аеруча истә калырлык булды. Бу кичәләрдән балалар да,әти-әниләр дә бик канәгать калдылар. Ай саен әти-әниләр почмагында кызыклы консультацияләр, киңәшләр яңартылып торылды, балаларның эшләре куелды. Ел буена 4 ата-аналар җыелышы үткәрелде,тәрбия темасына докладлар укылды.Бәйрәмнәрдә төшкән карточкаларны ясатып "Күңелле мизгелләр" дигән стендка куйдык. Апрель аенда ата-аналар һәм башлангыч сыйныф укытучылары очен "Ачык ишекләр" көне үткәрдек.

***БАЛАЛАР БАКЧАСЫНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ:***

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерү. Матур әдәбият, әкиятләр, халык авыз иҗаты, уеннар аша тормышка ашыру.

Төрле жанрдагы әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли белергә өйрәтү.

**Яңа уку елына бурычлар.**

1.Федераль белем бирү стандартын укыту-тәрбия процессында кулланып балаларның шәхси үзләштерү үзенчәлекләрен искә алып мәктәпкә әзерлекне булдыру.

2. Балаларны ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерү һәм сүз байлыгын арттыруда заманча технологияләр, УМК куллану.

3.Балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм үстерү, сәламәт яшәү нигезләрен формалаштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен төшендерү буенча балалар бакчасы һәм әти-әниләр белән тыгыз элемтәдә тору.

4.Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эзләнү - экспериментальь эшчәнлеген оештыру аша экологик тәрбия бирүне, экологик күнекмәләр формалаштыру.

5.Балаларда үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыру, аларның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган җирен хөрмәт итүче патриот шәхес тәрбияләү.

**П р о б л е м а:**

**ФГОС таләпләре нигезендә балаларга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеген оештыру**

**Балалар бакчасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшли:**

1. .ФГОС таләпләре буенча балаларда мөстәкыйльлек, инициатива, үз көченә ышанганлык, үзенә һәм башкаларга уңай мөнәсәбәт, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән актив бәйләнештә булу, иҗат итүгә, уйлап табуга, хыяллана белү , кызыксынучанлык, фикер йөртә белү сәләтләрен үстерү.

2.Халык педагогикасына нигезләнеп, балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирү.

3. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру.
4.Балаларга экологик тәрбия бирү, экологик күнекмәләр формалаштыруны дәвам итү.

**Балалар бакчасының методик темасы:**

Халык педагогикасы нигезләренә һәм федераль дәүләт белем бирү стандарларына таянып таянып, заман таләпләренә җавап бирердәй, һәрьяклап үсеш алган белемле һәм физик яктан сәламәт, көндәшлеккә сәләтле балалар тәрбияләү.

Кадрлар арасында эш бүленеше

| № | Эшчеләрнең Ф.И.О | Башкарган вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Галлямова Флюра Габдулхаевна | мөдир |
| 2. | Гайсина Регина Маликовна | тәрбияче |
| 3. | Шарипова Раушания Махияновна | кече тәрбияче |
| 4. | Гафурова Илсояр Хамзиевна | пешекче |

**Педагогларның белем күтәрү, аттестацияләү графигы**

| № п/п | Ф.И.О. | вазыйфасы | Белеме | Пед. стаж | Квалификацион категория | Белем күтәрү елы | Аттест. үтү елы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Галлямова Флурә Габделхай кызы | мөдир | югары | 35 | | 2024 | 2024 |
| 2 | Гайсина Регина Маликовна | тәрбияче | махсус урта | 1 | | | |

**Белем турында законнар үтәлеше**

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакчасының укыту-тәрбия планын төзү. | август | мөдир, тәрбияче |
| 2. | Белем һәм тәрбия бирү өчен кирәк – яракларны җитәрлек күләмдә булдыру. | август | мөдир |
| 3. | Белем һәм тәрбия бирүдә тиешле шартлар булдыру. | даими | мөдир |
| 4. | Балаларның туклануын югары дәрәҗәдә оештыру. | даими | мөдир |
| 5. | Льготаларга ия булган гаиләләрнең исемлеген булдыру. | сентябрь | мөдир, . |
| 6. | Балалар бакчасының көндәлек режимын, шөгыльләр челтәрен төзү, раслау. | сентябрь | мөдир, тәрбияче. |
| 7. | Балалар бакчасы һәм эти-әниләр арасында | август | мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | килешүләр төзү. | | |
| 8. | Сәламәтләндерү эше планы төзү. | август | мөдир |
| 9. | Эвакуация планын барлык эшчеләргә җиткерү, бүлмәләр буенча җаваплы кешеләр билгеләү. | сентябрь | мөдир |
| 10. | Инвентаризация үткәрү. | октябрь | мөдир |
| 11. | Тематик эш планнары төзү. | август | тәрбияче |
| 12. | Балаларның күңел ачу кичәләрен оештыру. | план буенча | тәрбияче |
| 13. | Балаларның иминлеген һәм хезмәтне саклау инструкциясе үткәрү. | кварталга бер тапкыр | мөдир |
| 14. | Бакчада эшчеләрне, аларның балаларын сәламәтләндерү буенча эш. | даими | мөдир |
| 15. | Балалар бакчасы, шифаханә һәм СЭС белән килешеп, балаларның исәнлеген, сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру. | даими | мөдир |
| 16. | Яңа уку елына бакчага килүче балаларның төгәл исемлеген булдыру. | май | мөдир, тәрбияче |

Тәрбиячеләрнең профессиональ осталыкларын үстерү.

| Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1. Педагогларнын үз белемнәрен күтәрү курслары | 2024 | Галлямова |
| 2. Аттестация | 2023-2024 | Тәрбияче,бакча мөдире |
| 3.Белем күтәрү планнары төзү һәм өзлексез эш алып бару | | Тәрбияче<br>Мөдир |

Тәрбиячеләрнең методик темалары

| № | ФИО | Темасы | Алынган вакыты | Тәмамлан-ган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Гайсина Регина | Уен һәм хезмәт эшчәнлеге аша экологик тәрбия биру | 2021 ел , сентябрь | 2023сентябрь |
| 2. | Галлямова Ф. | Халык педагогикасы аша балаларга хезмәт тәрбиясе бирү. | 2020 нче ел | 2023сентябрь |

Педагоглар киңәшмәләре

| № | Темасы | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2.<br><br><br><br><br><br><br><br>3.<br><br><br><br><br><br><br><br>4. | 1 нче пед.утырыш<br>Тема .*Балалар бакчасының яна уку елына эзерлеге*<br>Көн тәртибе:<br>1.Яңа уку елында педагогик коллектив алдында торган бурычлар. Яңа уку елына эш планнары кабул итү.<br>2. ФГОС таләпләренә туры китереп төзелгән тәрбияченен тематик планнары, дәресләр челтәрен кабул итү, режим, расписаниеләрне кабул итү<br>3. Балалар бакчасың яңа уку елына әзерлеге.<br><br>2 нче пед.утырыш<br>Тема. ФГОС кысаларында балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеген оештыру.<br>1. ФГОС таләпләре буенча тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру.<br><br><br><br>1.Әти-әниләр белән үткәрелгән анкета нәтиҗәләренә анализ<br><br>4 нче пед.утырыш.<br>1. Уку елына алынган бурычларның үтәлеше<br>2. Тәрбиянеңе ел буе эшләгән эшчәнлеккә отчеты, диагностика нәтиҗәләре | август<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Ноябрь<br><br><br><br><br><br><br><br>январь<br><br><br><br><br>май | мөдир<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Мөдир<br><br>Тәрбияче чыгышы<br><br><br>Тәрбияче<br>тәрбияче<br><br><br><br><br>тәрбияче<br>модир |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Семинар- практикум<br>ФГОС кысаларында балаларга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлеген оештыру | ноябрь | мөдир | Приказ<br>Чыгыш<br>Конспект<br>Әңгәмә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Икетеллелек буенча бакча эшчәнлеге | даими | | Приказ<br>Чыгыш<br>Протокол |

Тәрбиячегә консультацияләр, әнгәмәләр.

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның адаптация чоры | сентябрь | мөдир | әңгәмә |
| 2 | “Мәктәп һәм балалар бакчасы арасында дәвамчанлык планы буенча фикер алышу. | октябрь | мөдир | әнгәмә |
| 3 | Даими үткәрелә торган консультация , әнгәмә:<br>ФГОС, УМК буенча<br><br>Атналыклар планы буенча әнгәмә | ноябрь | мөдир | конспект |
| 4 | Балалар бакчасында проект эшчәнлеге | ноябрь | мөдир | конспект |
| 5 | Балалар белән табигатькә экскурсияләр үткәрү. | декабрь | мөдир | конспект |

2022-2023 нче уку елы өчен консультатив пунктның эш планы

| Үткәрү вакыты | Консультация темалары | Җаваплы |
|---|---|---|
| Сентябрь | Календарь тематик план төзү<br>Әти-әниләргә консультация. | Балалар бакчасы мөдире, тәрбияче |
| Октябрь | Бәйрәмнәр һәм күңел ачу чараларын планлаштыру<br>Өлкәннәр көне<br>Сөмбелә | Балалар бакчасы мөдире, тәрбияче |
| Ноябрь | Әниләр көне | Балалар бакчасы мөдире, тәрбияче |

| | | |
|---|---|---|
| Декабрь | “ Яңа ел” бәйрәменә бүлмәләрне бизәү<br>“Яңа ел” бәйрәменә әзерлек | Тәрбияче |
| Февраль | “Ватанны саклаучылар” көненә әзерләнү | Тәрбияче |
| Март | “8 Март – Халыкара Хатын-кызлар көне”нә әзерләнү | Тәрбияче |
| Апрель | “Кошлар көне” бәйрәменә әзерлек | Тәрбияче |
| Май | Җиңү бәйрәменә әзерлек.<br>Чыгарылыш кичәсенә әзерлек.<br>Сабантуйга әзерлек | Тәрбияче |

Ачык чаралар

| <u>№</u> | <u>Тема</u> | <u>Үтәү вакыты</u> | <u>Җаваплы кеше</u> | <u>Үтәү формасы</u> |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларны рус теленә өйрәтү | Октябрь | Тәрбияче | Конспект |
| 2 | Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү | Ноябрь | Тәрбияче | Конспект |
| 3 | Балаларга физик тәрбия. Иртәнге гимнастика, физкультминутлар | Февраль | Тәрбияче | Конспект |
| 4 | Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү шөгыльләрдә һәм режим моментларында | Апрель | Тәрбияче | Конспект |

Смотр – конкурслар

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | «Яңа уку елына әзерлек”. Районара балалар бакчалары арасында конкурс | Август | Мөдир |
| 2 | Рәсем конкурсы. «Алтын көз» | Октябрь | Тәрбияче |
| | “Без, сезнең белән, өлкәннәр” | Октябрь | Тәрбияче |
| 3 | «Минем әнием» темасына балалар эшләренә күргәзмә | Ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | Кар сыннары ясау. Авыл җирлеге оешмалары арасындагы конкурста катнашу | Декабрь | Тәрбияче |
| 5 | Иң матур Кыш бабай һәм Кар кызы.Рәсем конкурсы. | Декабрь | Тәрбияче |
| 6 | 8 нче мартка әниләр һәм балалар белән эшләгән эшкә конкурс | Март | Тәрбияче |
| 7 | 12 апрель көненә рәсем конкурсы | Апрель | Тәрбияче |
| 8 | Г.Тукай көненә шигырь һәм рәсем конкурсы. | Апрель | Тәрбияче |
| 9 | Юл йөрү кагыйдәләре буенча балаларның эшләренә конкурс | Апрель | Тәрбияче |
| 10 | Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышлап конкурс | Май | Тәрбияче |

Район буенча үткәрелә торган конкурслар

| № | тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Йолдызлык» конкурсы | Район планы буенча | | Сәнгать эшчәнлеге |
| 2 | “Ел тәрбиячесе-2023 | | | Файл тутыру |
| 3 | | | | |

**Аккуз балалар бакчасының**
**2022 – 2023 нче ел өчен күңел ачулар, бәйрәмнәр планы**

| № | Эчтәлеге | вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Күңелле стартлар | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2 | Өлкәннәр көне | Октябрь | Тәрбияче |
| 3 | “Сөмбелә” бәйрәме | Октябрь | Тәрбияче |
| 4 | Яшелчәләр - витаминнар хәзинәсе | Ноябрь | Тәрбияче |
| 5 | Әйдәгез ярышабыз | Ноябрь | Тәрбияче |
| 6 | Әниләр бәйрәме | Ноябрь | Тәрбияче |
| 7 | Хуш киләсең, Яңа ел | Декабрь | Тәрбияче |
| 8 | Әтиләр бәйрәме | Февраль | Тәрбияче |
| 9 | Уйныйбыз да, жырлыйбыз да | Март | Тәрбияче |
| 10 | Бүген әни бәйрәме | Март | Тәрбияче |
| 11 | Кошлар-безнең дуслар | Апрель | Тәрбияче |
| 12 | Карга боткасында | Май | Тәрбияче |
| 13 | Җиңү бәйрәме | Май | Тәрбияче |
| 14 | Чыгарылыш кичәсе | Май | Тәрбияче |
| 15 | Сабантуй | Май | Тәрбияче |

Атналыклар

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Саф һавада уеннар | сентябрь | тәрбияче |
| 2. | “Без сезнең белән горурланабыз, ветераннар” | октябрь | тәрбияче |
| | “Танып белү эшчәнлеге атналыгы”. | | |
| 3. | “Эксперименталь эшчәнлек» | ноябрь | тәрбияче |
| 4. | “Кышкы уеннар уйнау” | декабрь | тәрбияче |
| 5. | “Туган телдә сөйләшәбез “ | январь | тәрбияче |
| 6. | “Рус телендә сөйләшәбез” | февраль | тәрбияче |
| 7. | “Театр атналыгы” | март | Тәрбияче |
| 8. | “Экология атналыгы” | апрель | тәрбияче |
| 9. | | май | тәрбияче |

**Житәкчелек һәм контроль**
**Фронталь һәм тематик тикшерү**

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җавап-лы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тематик тикшерү<br>Балаларның сөйләм телен үстерү<br>Максат: балаларның сөйләм телен үстерүдә тәрбиячене эш алымнары | апрель | мөдир | приказ<br>күзәтү<br>әңгәмә<br>планга анализ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Фронталь тикшерү<br>Мәктәпкә әзерлек группасында балаларга белем һәм тәрбия бирү<br>Максат: балаларның мәктәпкә физик, интеллектуаль, психологик, эмоциональ әзерлеге | апрель | мөдир | справка<br><br>приказ<br>күзәтү<br>балалар белән әңгәмә<br>шөгыль |

**Оператив тикшерү**

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Группа булмәләренең санитар торышын тикшерү | Атнага 1 | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 2 | Группа, йокы булмәләрендәге мебель маркировкасы | Елга 2<br>Сентябрь, январь | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 3 | Урын-җир, сөлгеләр чисталыгы, маркировкасы | Айга 1 | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 4 | Кухняның санитар торышы | Атнага 1 | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 5 | Складның санитар торышы | Айга 1 | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 6 | Туклану режимы | Атнага 1 | | Күзәтү<br>Искәртү |
| 7 | Туклану посудаларының юылуы | Атнага 1 | Мөдир | Күзәтү<br>Искәртү |
| 8 | Ишек алдының чисталыгы | Атнага 1 | Мөдир | Күзәтү |

**Акку балалар бакчасында оператив тикшерү үткәрүнең циклограммасы 2022-2023 нче уку елы**

| | Дүшәмбе | Сишәмбе | Чәршәмбе | Пәнҗешәм- бе | Җомга | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | Яңа уку елына әзерлек | Тәрбиясенең документация ләре | Санитария-гигиена кагыйдәләре нең үтәлеше | Прогулка вакытында хәрәкәтле уеннар | Мебль маркировкалары | |
| Октябрь | Ашау вакытында балаларның культура –гигиена кагыйдәләре | Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүдә тәрбиясенең эшчәнлеге | 2022-2023нче ел башына диогностика. | Бүлмәләрне җиллләтү, язып бару | Санитария – гигиена-кагыйдәләренең үтәлеше | |
| Ноябрь | Рус теле коне уткэру. Проектордан файдалану | Кухняның санитар торышы | Табигать почмагында эш | Прогулка вакытында күзәтү | Күңел ачу кичәләренең беркетмәләре | |
| Декабрь | Иртәнге фильтр үткәрү | Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтүләре | Сюжетлы-рольле уеннар оештыру | Экскурсияләр планы үтәлеше | Яңа ел программасы | |
| Январь | Балаларның йөрешләре | Дезрастволар ясау дэфтэргэ язып бару. | Балаларның юыну вакытлары | Балаларның хайваннар дөньясы турындагы белемнәре | Рус теленнән йомгаклау шөгылләре | |
| Февраль | Иртәнге гимнасти- | Постель маркировкала | Кухняның санитар | Шөгыльләрдә проекторлар | Санитария-гигиена | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ка үткәрү | ры | торышы | куллану | кагыйдәләрене ң үтәлеше | |
| Март | Балалар белән индивидуаль эш | Балаларның ашау вакытлары | Санитария-гигиена кагыйдәләренең үтәлеше | УМК буенча кайткан күрсәтмә һәм таратма материалларны куллану өчен тртипләү | Программа таләпләре-нә туры китереп балаларның әвәләү күнекмәлә-ре | |
| Апрель | Бакчада санитария-гигиена кагыйдәләре үтәлеше | Прогулка вакытында хәрәкәтле уеннар | Экскурсияләр планы үтәлеше | Балаларның кул эшләре | Булмэ голлэрен карау,таблечкалары, анлатмаларын булдыру. | |
| Май | Участокның чисталыгы | Диагностикалар эшләү | Санитария-гигиена кагыйдәләре үтәлеше | Чыгарылыш кичәсенә әзерлек | Балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү | |

**Мәктәп белән элемтә планы**
**Методик эш**

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Утырышлар | | | |
| | - Мәктәп белән элемтә планы төзү | сентябрь | Педколлектив | |
| | Белем бирүнең сыйфатын күтәрү юллары һәм формалары | ноябрь | | |
| | - Балаларнын белем дәрәҗәләренә анализ | | Педколлектив | |
| | Башлангыч сыйныф укытучыларына ачык шөгыль күрсәтү | апрель | Педколлектив | Конспект |
| 2 | Башлангыч сыйныф укучыларынын дәресләрендә булу | апрель | | |
| 3 | Педагоглар белән эш | | | |
| | *Консультацияләр* | даими | Тәрбияче | |
| | Балаларны мәктәпкә әзерләү | | | Протокол |
| | Шәхси һәм социаль психологик әзерлек | | Педколлектив | |
| | Ихтыяри әзерлек | | | |
| 1 | | | | |
| 2 | Балалар белән эш | Ноябрь | | |
| | *Шөгыльләр* | Январь | тәрбияче | |
| 3 | Без – булачак укучылар | | | |
| | Мәктәп, класслар | Март | мөдир | |
| | Яраткан уенчыгым белән хушлашам | | | |
| | Мәктәпкә экскурсияләр | | | |
| | Белем бәйрәмендә катнашу | Ноябрь | тәрбияче | |
| | Әлифба бәйрәмен карау | Январь | мөдир | |
| | Яңа ел, кошлар көннәрендә катнашу | Апрель | | |
| | Башлангыч класс укучыларын бакчага | | тәрбияче | |
| | чакыру | Апрель | тәрбияче | |
| | Яңа ел бәйрәменә чакыру | Сентябрь | тәрбияче | |
| | Г.Тукайга багышланган шигырь | План буенча | тәрбияче | |
| | кичәсенә чакыру | Декабрь | тәрбияче | |
| | Сабантуй бәйрәменә чакыру | Апрель | тәрбияче | |
| | | Июнь | | |

## Ата-аналар белән эш

Сентябрь

1.Ата-аналар җыелышын уздыру. Тема: "Яңа уку елы алдында торган бурычлар."

- Еллык план белән таныштыру;
- Ата-аналар комитеты сайлау;
- Ата-аналар өчен булган кагыйдәләр белән таныштыру;
- Туклану, ата-аналар взносы турында информация бирү;
- Ата-аналар белән договорлар төзү.

2."Сак бул, грипп" дигән темага чыгыш ясау.

3.Педагогик консультация "Әдәплелек кагыйдәләре". Әти-әниләргә киңәшләр бирү.

Октябрь

1. Тема: "Гаилә һәм сәламәт яшәү рәвеше"

- Сәламәтләндерү бурычлары белән таныштыру;
- Сәламәтлек буенча диагностика нәтиҗәләре;
- Анкеталар, тестлар үткәрү.

2.Балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү өстендә бердәм эшне дәвам итү. Әңгәмә "Грипптан профилактика чаралары"

3.Баланың кызыксынучанлыгын, күзәтүчәнлеген үстерү, белергә, аңларга омтылышны ничек саклап калырга? Ата– аналар белән шәхси әңгәмәләр.

4.МКР буенча ата-аналарга балалар белән индивидуаль эш тәкъдим итү.

6.УМКдагы мультфильмлы дискларны карау, әкият,җырларны тыңлау өчен өйләренә бирү, аның турында бергәләп сөйләшергә тәкъдим итү.

6.Балалар бакчасы өчен түләүне тулысынча һәм вакытында башкару.

7.Өлкәннәр атналыгы кысаларында балалар белән әби-бабайларга бүләкләр ясау. Өлкәннәргә багышлап "Әбекәй-алтыным, минем иң якыным" күңел ачу кичәсе уздыру.

Ноябрь

1.Балаларны сәламәтләндерү, чыныктыру өстендә бергәләп эшләүне дәвам итү. Консультацияләр:- Салкын тиюдән ничек сакланырга? - Бармак уеннары ни өчен кирәк?

2.Группаны сарымсак, суган белән тәэмин итү.

3.Әниләр көне уңаеннан котлау открыткасы эшләү, әниләрне котлау.

4.Әниләр көненә багышланган "Җырлыйм әнием турында" дигән күңел ачу үткәрү.

5.Әниләр көненә багышланган ""Все краски жизни для тебя" дигән балалар иҗаты конкурсында катнашу.

Декабрь

1.Балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү өстендә бердәм эшне дәвам итү. Грипптан саклану чарасы буларак, лимон, сарымсак измәсенең файдасы. Ата-аналар белән әңгәмәләр, консультацияләр уздыру.

2. Әти-әниләргә консульция "6-7 яшьлек балаларының сөйләм үсеше өстендә эш".

3.Ата –анлар почмагына "Кышкы травмалардан сакланыгыз!"дигән темага информация.

4. Әти-әниләр өчен консультация «Ничек сәламәт бала үстерергә?»

5. "Яңа ел бәйрәме кичәсен үткәрү".

6. "Балагыз нинди уенчыклар белән уйный?" темасына консультация.

7. Мәйданчыкта сыннарны төзергә ярдәм итүне оештыру.

8. "Өйдә рәсем һәм әвәләү шөгыйльләрен ничек оештырырга?" темасына әти-әниләр белән индивидуаль әңгәмә уздыру.

Январь

1. Тема: "Балалар бакчасында балаларны икетеллелеккә өйрәтү, УМК лар куллану.

2. Балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү өстендә бердәм эшне дәвам итү. "Өшегәндә беренче ярдәм "консультация.

3. Баланың хәтерен үстерү өстендә ничек эшләргә (индивидуаль әңгәмәләр).
4. Балаларга шуу өчен тау ясауда ярдәм итүне оештыру.
5. “Иманлы бала” дигән темага ата-аналар почмагына ширма ясау.
6. Рус халык әкиятен сәхнәләштерү, эти-әниләргә күрсәтү.

Февраль

1.Балаларны сәламәтләндерү, чыныктыру өстендә эшне дәвам итү: Әңгәмә “Язгы витамин җитмәү чорын ничек җиңеләйтергә?”
2. Гадәттән тыш хәлләр вакытында үзеңне һәм гаиләңнесаклау чаралары хакында сөйләшү: “Сак булыгыз- язгы боз алдаучан!”“Балаларны янгын куркынычлыгыннан ничек сакларга?(профилактик чаралар турында әңгәмә)
3.УМКдагы мультфильмлы дискларны карау, әкият, җырларны тыңлау өчен өйләренә бирүне дәвам итү. Аның турында бергәләп сөйләшергә тәкъдим итү.
4.Туган тел атналыгын үткәрүгә эти-әниләрне ярдәмгә тарту: театрга кирәк-яраклар белән тәэмин итүне сорау.
5.Туган тел атналыгы кысаларында “Өч кыз” әкиятен сәхнәләштерү.
6.Әтиләргә бәйрәм бүләкләре әзерләп, аларны бәйрәм белән котлау. ”Ватанны саклаучылар көне “ уңаеннан этиләр белән “Ягез әле, этиләр”спорт ярышлары оештыру.

Март

1. Әниләргә, әбиләргә бүләкләр әзерләү.
2. 8 нче Март Халыкара хатын- кызлар көне уңаеннан әниләргә багышлап бәйрәм үткәрү. Әниләр белән “Ягез әле, әниләр” дигән ярыш кичәсе уздыру.
3.Консультация “Балалар травмалары һәм аларны кисәтү чаралары”.
4. Ата-аналар почмагына “Сулагайлык – кимчелекме?” дигән ширма эшләп кую.
5. “Әдәплелек кагыйдәләре” дигән искәрмә тарату.
6.”Әти-әни – спорт гаиләсе” дигән ярыш бәйрәме уздыру.

Апрель

1.Әти-әниләргә киңәшләр:“Балаларны сезонга карап киендерү”, “Язгы юллар бозлавык – сак булыгыз!”, “Язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма!”.
3.Авылда чисталык һәм пөхтәлек булсын өчен без нәрсә эшли алабыз? Әти-әниләр белән әңгәмә. Уен мәйданчыгын тәртипкә китерү, җәйге сәламәтләндерү чорына әзерләргә булышырга тарту.
4. Ата-аналар почмагына “Мультфильмнарны ничек сайларга?” дигән ширма эшләп кую.
5. Габдулла Тукайның шигырьләренә, әкиятләренә рәсем, аппликация, композицияләр ясау, күргәзмә оештыру.
6. “Габдулла Тукай – безнең күңелләрдә” дигән күңел ачу кичәсе уздыру.
7. Бөек җиңүнең 75 еллыгына багышланган “Бабам сугышта булган” фотокүргәзмәгә әзерлек. Әти-әниләрнең материал туплауларын дәвам итү.

Май

1.Җиңү көненә багышланган рәсемнәр күргәзмәсе.
2.Әти-әниләргә балалар белән район үзәгенә барып бәйрәм парадын карарга тәкъдим итү.
3. Балалар белән һәйкәл янында Җиңүгә багышланган чарада катнашу.
4.“Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләре “консультация.
5.Балаларның җәйге ялын дөрес һәм файдалы үткәрү өчен шартлар булдыру.
6. Ата-аналар җыелышы уздыру. Тема: “Балалар бакчасының уку йомгаклары”
- Балаларның мәктәпкә әзерлеге нинди була?
- Сез үз балагызга тиешле дәрәҗәдә игътибарлымы?
- “6 яшьлек бала ниләр белергә тиеш” дигән искәрмәләр тарату.
7. Әти-әниләр белән шәхси әңгәмәләр “Эчәк авыруларын һәм энцефалитлы талпан кадалуын кисәтү чаралары.”
8. Ата – аналар һәм балалар белән бергә Сабантуй бәйрәме уздыру.

**Бакчага йөрмәгән балалар белән эш**

| № | Тема | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше | Үтәү формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1<br><br>2<br><br>3 | Бакчага йөрмәүче балаларның өйләрендә булу, гаилә шартлары белән танышу<br><br>Бакчага йөрмәгән балаларны бәйрәмнәргә чакыру, туган көннәре, бәйрәмнәр белән котлап открыткалар җибәрү<br><br>Әти-әниләрен ата-аналар җыелышларына чакыру, бәйрәмнәргә чакыру | Ел дәвамында<br><br>План буенча<br><br>План буенча | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче<br><br>Мөдир | Әңгәмә<br><br>Әңгәмә<br><br>Әңгәмәләр үткәрү |

ТЕЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫ
ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Һәрбер балага ана телендә төрле яклап үсеш алу өчен шартлар ту-дыру, аралашу өчен телне сайлап алу иреге белән тәэмин итү. | ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 2 | Төркемдә тәрбия һәм белем бирү эшен туган телдә (татар телендә) оештыру. | ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 3 | Дәүләт телләре турындагы законны үтәү максатыннан, балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 4 | Тематик шөгыльләр үткәрү – “Татар телем-анам теле”, “Гаилә гореф-гадәтләре”, “Әбиемнең сандыгы” | план нигезендә | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 5 | Татар халык бәйрәмнәрен, күңел ачу иртәләре, атналыклар үткәрү- “Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Әниемә бүләгем”, “Әтием – минем горурлыгым”. | план нигезендә | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 6 | Габдулла Тукайның туган көненә | апрель | Бакча мөдире, тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | багышлап шигырь бәйрәме үткәрү, конкурсларда катнашу | | |

**Сәламәтләндерү, чыныктыру планы**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Бакчаның еллык “Балаларның сәламәтләндерү,чыныктыру планын”төзү. | август | мөдир, тәрбияче |
| 2. | ФИЗО почмакларын, спорт участокларын яңарту, атрибутлар белән тулыландыру. | даими | мөдир тәрбияче |
| 3. | Максатчан экскурсияләр оештыру. | даими | тәрбияче ярдәмчесе, тәрбияче |
| 4. | Хәрәкәтле уеннар өчен кулланма жиһазлар туплау. | даими | мөдир |
| 5. | Спорт бәйрәмнәре уздыру.<br>Хәрәкәт үстеру буенча күңел ачулар. | план нигезендә | тәрбияче |
| 6. | АЦРБ педиатры тарафыннан балаларны тикшерүләр, әңгәмәләр. | елга ике | тәрбияче |
| 7. | Иртәнге гимнастикаларны, физкультура шөгыльләрен үз югарылыгында үткәрү. | даими | тәрбияче |
| 8. | Санитария гигиена таләпләрен үтәү. | даими | тәрбияче ярдәмчесе, тәрбияче |
| 9. | Ата-аналар белән балаларның сәламәтлекләре турында әңгәмәләр уздыру. | даими | мөдир тәрбияче |
| 10. | Прогулкаларда хәрәкәтле уеннарны тиешенчә үткәрү. | даими | тәрбияче |
| 11. | Балаларны урамда кабул итү | +15 | тәрбияче |
| 12. | Ачык һавада иртәнге зарядка, һава ванналары | май - октябрь | тәрбияче |
| 13. | Фитонициды (суган, сарымсак) | октябрь - апрель | тәрбияче |
| 14. | Йокыдан торгач сулыш гимнастикалары | даими | тәрбияче |
| 15. | Тигезтабанлылыкны булдырмау өчен күнегүләр | даими | тәрбияче |
| 16. | Сәламәтлек көне | план нигезендә | мөдир тәрбияче |

**Аккуз балалар бакчасының**

## 2022-2023 нче ел өчен экскурсияләр планы

| № | Экскурсияләр | Вакыты | Җаваплы кеше | Үтә-леш |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Яланга экскурсия | Сентябрь | Гайсина<br>Гайсина | |
| 2 | Якындагы урманга экскурсия | Октябрь | Гайсина | |
| 3 | Китапханәгә экскурсия | Ноябрь | Гайсина | |
| 4. | Мәдәният йорты янындагы кышкы сыннар янына экскурсия | декабрь | Гайсина | |
| 5. | Китапханәгә экскурсия | Январь | | |
| 6. | Мәчеткә экскурсия | Февраль | Гайсина | |
| 7. | Басуга экскурсия | Март | | |
| 8. | Чишмәгә экскурсия | Апрель | | |
| 9. | Аланлыкка экскурсия | Май | Гайсина | |

Производство киңәшмәләре

| Эчтәлеге | вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|
| 1.Тема.Балалар бакчасының эчке тәртип кагыйдәләре<br>Көн тәртибе:<br>1.Балалар бакчасының эчке тәртип кагыйдәләрен аңлату<br>2.Үзебезнең балалар бакчасында эчке тәртип кагыйдәләренең үтәлеше.<br>3. Эш сәгатьләре, эш графигы белән танышу | сентябрь | Галлямова |
| 2.Тема. Локаль актлар белән танышу.<br>Көн тәртибе.<br>1. Алдагы производство киңәшмәсенең үтәлеше.<br>2. Эшчеләрне локаль актлар белән таныштыру<br>-Положение по профилактике несчастных случаев с воспитанниками<br>- Положение об экскурсиях<br>3. Өлкәннәр көне, Сөмбелә бәйрәмнәре үткәрү турында сөйләшү | Октябрь | Галлямова |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 3 Көн тәртибе:<br>. Оператив тикшерү нәтиҗәләре белән танышу<br>Әниләр көненә әзерләнү, эш бүлешү<br>- Локаль акт белән танышу. Положение о пожарной безопасности | ноябрь | Галлямова |
| 4. 1.Яңа ел бәйрәменә әзерлек<br>2.Кар сыннары ясау, бүлмәләрне бизәү. | декабрь | Гайсина |
| 5. 1.23 февраль бәйрәмен үткәрү турында<br>2. М.Җәлил туган көнне үткәрү турында | февраль | Гайсина |
| 6. 1.8 Март-халыкара хатын –кызлар көнен үткәрү<br>2.Бәйрәм вакытында техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре | март | Гайсина |
| 7. Габдулла Тукай туган көнгә шигырь бәйрәме үткәрү турында сөйләшү | апрель | Гайсина |
| 8. Балаларны озату, сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү турында сөйләшү<br>Язгы эшләр<br>Җәй көнендә бакча , чәчәклекләрне карау буенча дежурлык графигы эшләү. | май | Галлямова<br>Гайсина |

**Административ – хуҗалык эше**

| № | Эшнең эчтәлеге | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасын яңа уку елына әзерләү | август | мөдир |
| 2 | Утыртылган яшелчә, җиләк-җимешләрне жыйнау. | сентябрь | коллектив |
| 3 | Хезмәткәрләрнең гомуми җыелышын үткәрү | сентябрь | мөдир |
| 4 | СанПиН кагыйдәләренә туры китереп, группадагы мебельләрне ремонтлау, маркировкалау | сентябрь | коллектив |
| 5 | Участокларны чистарту, чүпне түгү | октябрь | кече тәрб. |
| 6 | Авыл җирлеге буенча үткәрелгән «Кар сыннары» конкурсында катнашу | декабрь | . коллектив |
| 7 | Ишек алдын, участокны көрәп тору | декабрь | кече тәрб. |
| 8 | Участокны кардан чистарту | даими | кече тәрб |
| 9 | Бәрәңге, яшелчә, чәчәкләр утырту | апрель, май | коллектив |
| 10 | Ремонт эшләре үткәрү | май | коллектив |